## Әниемә теләкләр

/Укучылар иҗаты/

«Әни» диеп язып куйдым
Яңа яуган ак карга.
Таптамагыз, һич ярамый
«Әни» сүзен таптарга.

Әни – җирдә иң газиз, якын кеше. Мин мәктәптән кайтуга, өйдә тәмле ис таралган була. Әнием инде тәмле-тәмле ризыклар пешереп куярга да өлгергән! Без аның белән тәмләп чәй эчәбез, серләребез белән уртаклашабыз. Ял көннәрендә без саф һавада йөрергә яратабыз. Әнием мине һәр кичне назлап йоклата, ә иртән "кызым" диеп сөеп уята. Нинди зур бәхет! Ярый әле, әнием, янәшәмдә син бар! Әнием, мин сине бик яратам! Сиңа иң изге теләкләремне генә телим. Әниемнең җылы кочагы..

*Айшә Галиәскарова, II сыйныф укучысы*

## Әнием догалары

Әни! Нинди ягымлы һәм йөрәккә якын бу сүз. “Әни” дип эндәшә алу зур бәхеттер ул, кеше өчен. Әни һәр кеше өчен иң кадерле, иң хөрмәтле, иң якын кеше ул. Авыр чакта да, шатлыклы минутта да без әниләр кочагына сыенабыз. Әниләрнең йөрәк җылысы, эндәшкән ягымлы сүзләре безгә яшәргә көч бирә. Йомшак куллары белән башны сыйпап үзса, бөтен авырулар, борчулар онытыла сыман. Шундый бөек, тылсымлы көчкә ия әниләр.

Һәркемгә үз әнисе дөньядагы иң кадерле кеше булган кебек, миңа да үз әнием – кадерлеләрдән дә иң кадерлесе. Ул безнең өчен һәрвакыт үз-үзен корбан итәргә әзер тора, авыр вакытта ярдәмгә килеп, киңәш бирә.

“Җәннәт – аналарның аяк астында” дип юкка гына әйтмәгәннәр. Әйе, бу дөрестән дә шулай. Һәрбер ана үзенең йөрәк җимеше – баласы өчен кайгырып яши. Бөтен авырлыкны үз йөрәгенә аша уткәрә, баласының тормышын җиңеләйтү өчен утка-суга керергә әзер тора. Әниләрнең балаларына кылган догасы һәрвакыт кабул була ул. Шуңа күрә әниләр догасыннан аерылга язмасын.

*Виктория Нукина, XI сыйныф укучысы*

/ Безнең уңышлар /



17 март көнне Аксубайның В.Г.Тимирясов исемендәге 1 нче мәктәбендә **"Тере классика"**исемле Бөтенроссия яшүсмерләр конкурсының муниципаль этабы булып узды. Бирелә укучылар төрле әсәрләрдән яттан, сәнгатьле итеп, өзекләр укыдылар. Безнең мәктәптән бу конкурста катнашкан укучылардан V сыйныф укучысы **Насыйрова Кәүсәр** призёр исеменә лаек булды. VI сыйныфтан **Вәлиев Ибраһим** һәм X сыйныфтан **Шичкина Карина** сертификатлар белән бүләкләнделәр.

Шулай ук районда үткәрелгән **“Без бергә”** конкурсында катнашып, Насыйрова Кәүсәр зона турына үтте. 22 нче мартта ул Болгар шәһәрендә 5 районнан килгән көндәшләре арасында чыгыш ясады. Кәүсәрнең җиңәсенә ышанып, уңышлар теләп калабыз.

*Мәрьям Вәлиева, VI сыйныф укучысы*

/ Безнең спорт /



18 нче март көнне Аксубайның ''Юность''спорт комплексында район башлыгы призына локаль конфликтларда һәлак булган якташ-сугышчылар һәм ветераннар истәлегенә багышланган милли көрәш буенча ачык турнир уздырылды. Бәйгедә Чирмешән, Чистай, Әлки, Норлат һәм Аксубай районнарыннан спортчылар катнашты. Нәтиҗәдә, Аксубай командасы гомумкоманда зачетында җиңү яулады. Бу җиңүгә мәктәбебез көрәшчеләре аеруча зур өлеш кертте. Үзләренең яшь һәм авырлык төркемнәрендә **Зөлфәт Замалетдинов**, **Абдулла Хәбибрахманов**, **Илдус Камалов** беренче урыннарны яуладылар. **Рияз Галимов** белән **Илнур Камалов** икенче урыннарны алуга ирештеләр. Җиңүче көрәшчеләр грамоталар, медальләр һәм акчалата призлар белән бүләкләнделәр. Төп бүләк – ярышларның абсолют батыры исеменә **Илдус Камалов** лаек булды. Яшь көрәшчеләрнең остазлары – **Илһам абый Камалов** яшьләр арасында көрәш спортын популярлаштырганы, спортчыларны тәрбияләгәне һәм үстергәне өчен **район башлыгының Рәхмәт хатына лаек булды**.

11 март көнне Әлки районында узган билбау көрәше турнирында **Илдус Камалов** икеләтә җиңүче булып кайтты. Ул үз авырлыгында яшүсмерләр һәм ир-егетләр арасында да беренчелекне яулады.

Безнең көрәшчеләр 12 март көнне Чистай шәһәрендә бертуган Гимадиевлар истәлегенә багышланган көрәш турнирында матур көрәш алымнары, осталыкларын, физик яктан нык булуларын һәм җиңүгә зур омтылышларын күрсәтеп, зур җиңүләр белән кайттылар. Үз авырлык төркемнәрендә **Замалетдинов Зөлфәт** – 1, **Хәбибрахманов Абдулла** белән **Галимов Рияз** – 2, **Хәбибрахманов Әхмәт** – 3 урыннарны яуладылар.

11-19 март көннәрендә Казан шәһәрендә балалар һәм яшүсмерләр арасында шахмат буенча Россия Кубогының беренче этабы үтте. Әлеге турнирда барлыгы Россиянең төрле төбәкләреннән 293 спортчы катнаша. Бу мәртәбәле ярышта, безнең 6 сыйныф укучысы **Фаил Гафиятуллин** да катнашып, икенче унлыкның уртасында урын алуга иреште.


**Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе**
**Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина**
**Редколлегия әгъзалары: Әминә Туктамышева, Виктория Нукина, Зөлфирә Сафиуллина**



# Мәктәп хәбәрчесе

**№3**
**(№44)**
**март**
**2023 ел**

***Түбән Майна урта мәктәбе газете***

**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**


## Алда дәүләт имтиханнары

/ Мөгаллим минбәре /

Барыбызга да билгеле булганча, математика фәненнән Дәүләт имтиханнарын тапшыру чыгарылыш сыйныфлар өчен мәҗбүри бурыч булып тора. Хәзерге чор имтихан материаллары предмет буенча белемне тикшерүгә генә түгел, ә аларны төрле практик бурычларны хәл итү өчен куллана белүгә дә юнәлдерелгән. Икенче төрле итеп әйткәндә, имтихан тупланган белемнәрне тормышта очрый торган мәсьәләләрне чишүдә куллана белүне тикшерә.

IX сыйныф укучыларын математикадан төп дәүләт имтиханына (ТДИ) әзерләү – укучы, укытучы, мәктәп администрациясе һәм әти-әниләрнең бергәләп системалы эшләве ул. Бу катлаулы “механизм”дагы бер генә чылбыр үз эшен тиешенчә башкармаса, имтиханның нәтиҗәсе көтелгәнчә булмый. Сынауда начар билге алу куркынычын кимету өчен нәрсәләр эшләргә? Бу сорау күпләрне борчый. Һәр педагогның үзенә генә хас эш алымнары була, бигрәк тә укучыларны имтиханнарга әзерләгәндә. Мин үзем дә укчыларны моңа әзерлим һәм эшемне түбәндәге юнәлешләрдә алып барам:

1. Агымдагы елда математикадан ТДИ уткәрүдәге үзенчәлекләрне өйрәнү. Һәр елны ТДИ уткәрү тәртибендә дә, бәяләүдә дә үзгәрешләр булып торырга мөмкин. Бу юнәлешне тормышка ашыруда укытучы эшчәнлеге мәктәп администрациясе белән нык бәйләнгән. Агымдагы уку елындагы ТДИ үткәрү кагыйдәләрен укытучы бар нечкәлекләре белән белергә тиеш. Администрациянең вазифасы – имтихан үткәрүдәге үзенчәлек һәм яңалыкларны укытучыларга җиткерү.

2. ТДИ үткәрү кагыйдәләре белән укучыларны һәм әти-әниләрне таныштыру. Укытучы ТДИга бәйле документларны үзе өйрәнгәннән соң укучыларга һәм аларның әти-әниләренә җиткерә. Алар кагыйдәләрне кабул иткәннән соң, укытучы белән хезмәттәшлек башлана. Кызганычка каршы, ТДИ буенча күп кенә документлар уку елы уртасында гына кабул ителә. Ә аңарчы узган уку елындагы кагыйдәләр белән эшләргә туры килә.

3. Укучыларның имтиханга әзерлек буенча дәрестәге һәм дәрестән соңгы эшчәнлекләрен оештыру. Монда укучыларга үзләренең әзерлек дәрәҗәсен бәяләү һәм «проблемалы зона»ларны билгеләү өчен барлык мөмкинлекләрне дә кулланырга кирәк.

4. Укучыларны дөрес итеп бланклар тутырырга өйрәтү. Дөрестән дә, имтиханга ныклап әзерләнеп тә, бланклар белән эшли белмәгән укучының нәтиҗәсе түбән булырга мөмкин. Шуңа күрә укытучы IX сыйныф укучыларын бланкларны дөрес тутырырга өйрәтергә тиеш. Бу эшне алар биреп карау имтиханнарында башкара.


*(Башы, дәвамы 2нче биттә)*


## III чирек нәтиҗәләре

/ Рәсми хәбәрләр /

24 март көнне 2022-2023 нче уку елының 3 нче чирегe төгәлләнде. Чирек нәтиҗәләре буенча мәктәптә белем сыйфаты 56,7% тәшкил итте. 46 укучының 37сенә чирек билгеләре чыгарылды (1нче һәм 10-11нче сыйныф укучыларына чирек билгеләре 3нче чиректә чыгарылмый) : чирекне 16 укучы "4" һәм "5" билгеләренә, ә 5 укучы бары тик "5" ле билгеләренә генә төгәлләде. Уку алдынгыларыбыз – II сыйныфтан **Закиров Инсаф** һәм **Камалов Ильнур,** III сыйныфтан **Нурматова Асия**, V сыйныфтан **Закирова Ләйсән**, VI сыйныфтан **Гафиятуллин Фаил**.

Бу чиректә IX сыйныф укучылары рус теленнән имтиханга керү буенча йомгаклау әңгәмәсе үттеләр. Аларның барысы да бу сынауны уңышлы башкарды. Уку елының иң озын чирегe тәмам, алда укучыларны язгы каникуллар көтә. IV чирек 3нче апрельдән башланып китәчәк.

*Илдар Сафиуллин, укыту эшләре буенча директор урынбасары*

## 2023 нче елда Дәүләт йомгаклау имтиханнары үткәрү графигы

| IX сыйныф | XI сыйныф |
| --- | --- |
| 24 май – тарих, физика, биология; | 26 май – география, литература, химия; |
| 30 май – җәмгыять белеме, информатика, география, химия; | 29 май – рус теле; |
| 6 июнь – рус теле; | 1 июнь – математика (база һәм профиль); |
| 8 июнь – математика; | 5 июнь – тарих, физика; |
| 14 июнь – литература, физика, информатика, география; | 8 июнь – җәмгыять белеме; |
| 17 июнь – җәмгыять белеме, биология, химия | 19, 20 июнь – информатика. |

***(Дәвамы, башы 1нче биттә)***

IX сыйныф укучылары белән әзерлек эшен сентябрь аеннан ук башлыйм. Аларга 8 эштән торган тест тәкъдим ителә: 3 бирем – «алгебра», 2 бирем – «геометрия», 2 бирем – «реаль математика» модуленнән һәм тагын 1 бирем – теләсә-кайсы модульдән. Эшнең нәтиҗәсенә карап, укучылар ике төркемгә бүленә. Беренче төркемдә – эшне үти алмаучылар, ә икенче төркемдә – 8 балл җыючылар. Һәр төркем өчен консультацияләрне аерым үткәрәм.

Әлбәттә, сыйфатлы әзерлек өчен дәрестән тыш консультация эше генә җитми. Шуңа күрә түбәндәге эш төрләрен дә кулланырга тырышам:

- дәрес вакытында өйрәнгән материалны кабатлаганда шул темага караган ТДИ биремнәрен чишү;
- эти-әниләр белән берлектә өйдә мөстәкыйль әзерлекне булдыру, ә авырлык тудырган биремнәрне консультациядә бергәләп карау;
- онлайн режимда имтиханнар биреп карау (http://uztest.ru/);
- укучыларны һәм аларның эти-әниләрен ТДИ га әзерләүгә юнәлтелгән электрон ресурслар белән таныштыру (http://sdamgia.ru/, http://alexlarin.net/, http://fipi.ru/, http://mathgia.ru/, http://4ege.ru/gia-in-9/ һ. б.);
- мәктәптә ТДИ форматында системалы рәвештә имтиханнар биреп карау һәм нәтиҗәләрен анализлау (дәресләр эш программасындагы резерв дәресләрдән алына). Бу эштә Статградтан алынган эшләргә еш мөрәҗәгать итәм.

Укучыларны дәүләт имтиханнарына әзерләгәндә түбәндәге эшчәнлекләрне иң кирәклеләре дип саныйм:

- укытучының үз белемен күтәрү өстендә эшләве;
- дәрестән тыш чаралар (түгәрәкләр, консультацияләр);
- Интернет-ресурслар белән эшләү;
- психологик әзерлек;
- дәреснең нәтиҗәлелеген күтәрү;
- таратма материал туплау;
- кабинеттагы эшчәнлек (информацион стенд);
- мониторинг үткәрү.

Бердәм дәүләт имтиханнары чыгарылыш сыйныф укучылары өчен генә түгел, ә укытучылар, эти-әниләр өчен дә зур сынау булып тора. Барыбызга да әлеге сынауларны уңышлы үтәргә насыйп булсын!

***Фәнил Зарипов, математика укытучысы***

***/ Мәктәп тормышы /***

## *Яшь инспекторлар кунаклар кабул итте*



Яшь инспекторлар хәрәкәтенең рәсми туган көне буларак 1973 елның 6 марты санала. Бу көнне ВЛКСМ Үзәк Комитеты Секретариаты, СССР Эчке эшләр министрлыгы коллегиясе, СССР Мәгариф министрлыгы коллегиясе карары белән хәрәкәтнең яшь инспекторлары отрядларын булдыру турында Нигезләмә расланган. Әмма балаларны юл-транспорт травматизмын профилактикалау эшенә күпләп җәлеп итү моңа кадәр үк башланган була. 1960 нчы елларда Мәдәният һәм ял паркларында урам хәрәкәтен имитацияләгән балалар мәйданчыклары төзелә башлый. Балалар яшьтәшләре арасында юл хәрәкәте кагыйдәләре нигезләре белемнәрен таратуда ярдәм күрсәтәләр. Аеруча актив укучылар үз теләкләре белән оешкан төркемнәргә берләшәләр: «яшь дружинниклар», «милициянең яшь дуслары», «ЮХИДИ ның яшь дуслары» һәм башкалар.

1973 нче елда хәрәкәтнең яшь инспекторлары отрядлары оештырылгач, ЮИД эшчәнлеге интенсив үсеш ала башлый. 10 айдан да кимрәк вакыт эчендә ил территориясендә 14 меңгә якын отряд оештырыла, төрле слетлар һәм ярышлар башлана. Мәктәп укучылары юл хәрәкәте кагыйдәләрен өйрәнә, кабинетлар һәм хәрәкәт иминлеге почмаклары җиһазландырыла, ачык агитация, башка тематик массакүләм чаралар үткәрелә. ЮИДның беренче Бөтенроссия слетына "Орленок" пионер лагерына 1975 нче елның сентябрь ахырында РСФСРның 72 төбәгеннән 870 иң яхшы ЮИДчы килә.

2023 нче елның 6 мартында ЮИД хәрәкәтенә 50 яшь тулды. Әлеге форсаттан безнең мәктәп территориясендә эшләп килүче ЮИД түгәрәге ТБ ГБУ БДД бүлекчә җитәкчесе Г.Х.Гималтдинова һәм Аксубай районы буенча юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлек юнәлеше муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы белгече Т.А.Мартынованы кунакка дәште. Көн тәртибе 3 өлештән торды. Алдан укучылар чыгышы, аннан соң юл хәрәкәте кагыйдәләрен белүгә викторина уздырылды. Ярыш ахырында командаларга истәлекле бүләкләр тапшырылды. Соңыннан ЮИДчылар кызлар һәм хатын- кызларны якынлашып килүче Халыкара хатын- кызлар көне белән тәбрик иттеләр.

***Руфия Гафиятуллина , "Яшь инспекторлар" түгәрәге җитәкчесе***

***/ Безнең бәйрәмнәр /***

## *Кызлар бәйрәме*




Яз кояшы күзләрне иркәләгән, табигатькә җан өргән мәлдә хатын-кызлар бәйрәмен билгеләп үтәбез. Күктәге кояш та бу бәйрәмгә бер дә кызганмыйча җылы нурын сибә. Әниләребезне шул җылылык белән чагыштырадыр кебек ул. Хатын-кыз өйдә җылылык, яктылык тудыручы булгангадыр, бәйрәме дә нәкъ менә шушы вакытка туры килә.

Кадерле хатын-кызлар! Сез булганда өйләр ямьле, чәйләр тәмле. Тукай әйтмешли, илһам чыганагы булганда, ир-егетләр дә көчле булыр; эшкә, иҗатка, ачышларга, тауларны буйсындырырлык рухи көчкә этәргеч булырсыз. Ир-егетләр ышыгында имин калып, сәламәт булып, матур булып, өйләребезнең йөзек кашыдай ялтырап яшәсәк иде.

Мәктәптә кызларга багышланган бәйрәм үзенчәлекле чара белән үтте. Башлангыч сыйныфлар үз әниләре белән бергә үткәргән булсалар, 5-11 сыйныфлар 2 командага бүленеп КВН уздырдылар. "Тургай" һәм "Умырзаялар" командасы үзләренең бар көчләрен куеп ярыштылар. Һәрбер конкурста да командалар үзләрен актив күрсәттеләр. Булсын ул открытка ясау, бию, шигырь сөйләү, пакетны дөрес саклау киңәше – безнең кызлар барсын да булдырдылар. Чыгарган нәтиҗәләр буенча "Тургай" командасы җиңү яулады. Ахырдан һәрберебезгә укытучылар бүләкләр өләшеп чыктылар. Бу бәйрәм белән катнашучылар да, тамашачылар да канәгать калдылар дип уйлыйбыз. Киләсе бәйрәмнәр дә шулай матур үтсен дигән теләктә калабыз.

***Әминә Туктамышева, XI сыйныф укучысы***

## *Нәүрүз мөбарәк булсын!*





Март ае матур, зур бәйрәмнәр алып килә. Шуларның берсе – Нәүрүз бәйрәме. Бу бәйрәм безгә борынгы бабаларыбыздан ук, буыннан-буынга күчеп килгән. Кышлар үтеп, табигать яңара башлагач, көннең төн белән тигезләшкән бер мәлендә, кешеләр "Нәүрүз" бәйрәмен билгеләп үткәннәр. Фарсыча "Нәү" – яңа, "рүз" – көн дигәнне аңлата. Көнчыгыш календаре буенча бу – Яңа елны каршылау бәйрәме. Менә шушы борынгы шәрык бәйрәме безнең көннәрдә халык йоласы буларак яңартыла.

Әлеге бәйрәм безнең мәктәптә дә бик күңелле үтә. Бу көнне мәктәп укучылары гына түгел, ә бөтен авылыбыз зур шатлык, рәхәтлек кичерә. Олысы-кечесе мәктәп бинасы янына ашыга. Бу көндә укучылар һәм укытучылар атлар бизәп, гармуннар белән җырлый-җырлый урам әйләнәләр. Авылны йөреп кайткач, Нәүрүзбикәне каршы алулар, Кыш бабайны озатулар җыр-биюләргә, матур шигырь юлларына үрелеп бара. Шулай ук коймак пешереп чәй эчүләр дә кергән бәйрәм программасына. Сыерчыклар кайткан вакытка, уңган-булган укучыларыбыз оялар ясаганнар. Бәйрәмдә иң матур, иң яхшы, иң зәвыклы кош оясы конкурсына нәтиҗә ясалды. Ул ояны – IV сыйныф укучысы Донсков Артур ясавы ачыкланды. Конкуста катнашучы һәр укучыга мәктәп директоры Рафик абый Насыйров бүләкләр тапшырды. Ә инде бәйрәмнең иң кызык өлеше – ярминкә. Монда һәр укучы катнаша. Алар өйләрендә әзерләгән тәм-томнарны, ашамлыкларны; коймак, кош теле, тагын әллә ниләр- барын да санап бетереп булмый, сатуга тәкъдим итәләр.

Бәйрәм бер-беребезгә матур теләкләр теләү белән тәмамлана. Барча кешеләр дә бәхетле булсын, бер-беребезгә карата ягымлы булыйк, табигатьне саклыйк, елгаларыбызның сулары саекмасын, зәңгәр күгебезне кара болыт капламасын, икмәкләребез мул, илләребез тыныч булсын!

***Вәсилә Залиева, VI сыйныф укучысы***

***/ Котлыйбыз!/***



Март аенда дөньяга килгән хөрмәтле укытучыбыз **Гафиятуллина Фәнүзә апаны**, бакчага йөрүче **Хәбибрахманова Асияне**, укучылардан **Әхсәнова Мәдинәне, Вәлиев Ибраһимны**, **Сафиуллина Зөлфирәне**, **Морадимов Илсурны** туган көннәре белән котлыйбыз! Аларга эшләрендә һәм укуларында уңышлар, ныклы сәламәтлек, барлык уй-теләкләренең чынга ашуын телибез!